| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОЛГАР ШӘҺӘРЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 9 « 29 » гыйнвар 2021 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының «гемодиализ үткәрүгә мохтаҗ затларга транспортта йөрү чыгымнарын билгеләү һәм түләү тәртибен раслау турында»2020 елның 1 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәваланучы затларга амбулатор гемодиализ узу урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы бурычларына карата, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының 2020 елның 1 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәваланучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында Карар кабул ителде:

1) Тәртипнең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә пособие алуга гариза белән мөрәҗәгать иткән айның беренче числосына кадәр».

2) Тәртипнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Айлык компенсация күләме, факттагы чыгымнардан чыгып, гемодиализ үткәрү урынына бару бәясен киметү юлы белән, тик бер бару

документларында күрсәтелгән бер йөрү өчен 1300,00 сумнан да артмыйча йә медицина белешмәсендә күрсәтелгән айга гемодиализ үткәрү буенча йөрү бәясе турындагы белешмәдә билгеләнә».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Болгар шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Костина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД БОЛГАР» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1637005440